**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның «16» июленнән

№ 11-77

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре» эше турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкының коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу практикасын үстерү, коррупция күренешләре фактларын ачыклау өчен шартлар тудыру максатларында, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре» эше турындагы нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»ннән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен алу буенча эш төркеме составын расларга (2 нче кушымта).
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек итү комиссиясе рәисенә йөкләргә.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы

Е. А. Тарнавский

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2026 елның «16» июлендәге
11-77 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре» эше турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгына коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»нең эш тәртибен билгели.

2. Коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»нә гражданнарның Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендәге коррупция турында мәгълүматны үз эченә алган үтенечләре кабул ителә.

3. Коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре» Яңа Чишмә ав., Совет ур,. 80 нче йорт адресы бунча Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 1 нче катындагы фойеда; Яңа Чишмә авылы, Май ур., 8 нче йорт адресы буенча «Яңа Чишмә үзәк район хастаханәсе» ДАССУнең беренче катындагы фойеда; Яңа Чишмә ав., Завод ур., 22 нче йорт адресы буенча «Слобода» ҖЧҖнең беренче катындагы фойеда; Яңа Чишмә ав., Заливная ур., 4 нче йорт адресы буенча район мәдәният йортының беренче катындагы фойеда; Яңа Чишмә ав., Ленин ур.,102 нче йорт адресы буенча «Яңа Чишәмә хәбәрләре» газетасы редакциясе бинасында; Яңа Чишмә ав., Ленин ур., 37 «А» адресы буенча «Яңа Чишмә муниципаль районы күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе филиалының беренче катындагы фойеда урнаштырыла.

4. Коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре» эшчәнлегенең төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) Гражданнарның Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә коррупция турында мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгатьләрен тиз кабул итү, исәпкә алу һәм карауны тәэмин итү;

2) мөрәҗәгатьләрне эшкәртү, тиешле чаралар кабул итү, шул исәптән әлеге мәсьәләләрне карау һәм законнарда билгеләнгән чараларны кабул итү өчен компетенциясенә керә торган дәүләт һәм муниципаль органнарга җибәрү;

3) язма мөрәҗәгатьләрне анализлау, коррупциягә каршы көрәш буенча күрелә торган чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатында аларны гомумиләштерү.

2. Эшне оештыру тәртибе

5. Коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»нең эшчәнлеге һәм эш режимы турындагы мәгълүмат халыкка «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасы, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайты аша җиткерелә.

6. Коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре» Яңа Чишмә муниципаль районы Советының гомуми бүлеге

мөһере белән мөһерләнә һәм «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»ннән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен алу буенча эш төркеме әгъзаларының имзалары белән таныклана.

7. Коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»нән гражданнарның язма мөрәҗәгатьләрен алу буенча эш төркеме әгъзалары тарафыннан айга кимендә бер тапкыр башкарыла һәм әлеге нигезләмәгә кушымта нигезендә коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләреннән» гражданнарның мөрәҗәгатьләрен алу акты белән рәсмиләштерелә.

8. Гражданнарга коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»нә керү эш вакытында 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр гамәлгә ашырыла.

9. Язма мөрәҗәгатьләрне алганнан соң һәм аларны теркәгәннән соң, мөрәҗәгатьләр алар белән алга таба эш итү буенча карарлар кабул итү өчен, Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгына җибәрелә.

## 3. Мөрәҗәгатьләрне теркәү һәм исәпкә алу

10. Коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре» аша килгән язма мөрәҗәгатьләрне теркәү һәм исәпкә алу, коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе тарафыннан, гражданнарның коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре» аша кергән язма мөрәҗәгатьләрен теркәү журналын алып бару юлы белән тормышка ашырыла (алга таба - Журнал).

11. Журнал битләре номерланырга, тегелергә һәм түбәндәге реквизитларга ия булырга тиеш:

1) мөрәҗәгатьнең тәртип номеры;

2) коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденцияләр өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»ннән алу (кабул итү) вакыты;

3) мөрәҗәгать иткән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме; аноним мөрәҗәгать килгән очракта, «аноним» билгесе куела;

4) мөрәҗәгать итүченең адресы һәм аның контакт телефоны номеры (әгәр белешмәләр булса);

5) мөрәҗәгатьнең кыскача эчтәлеге;

6) Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының резолюциясенең эчтәлеге һәм датасы;

7) мөрәҗәгатькә карата кабул ителгән чаралар турында билге.

12. Коррупция мәсьәләләре белән бәйле булмаган мөрәҗәгать килгән очракта, ул алга таба эшләү өчен Яңа Чишмә муниципаль районы Советының гомуни бүлегенә җибәрелә. Коррупция мәсьәләләре белән бәйле булмаган һәм әзерләнә, башкарыла торган яки башкарылган законсыз эш турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки башкарган зат турында мәгълүматларны үз эченә алмаган аноним мөрәҗәгатьләр карала, ләкин җавапсыз калдырыла.

13. Цензурасыз сүзләр булган мөрәҗәгатьләр эшкә кушылмый. Вазыйфаи затларның гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына куркыныч янаган цензурасыз яисә мыскыллау сүзләр булган мөрәҗәгатьләр тиешле органнарга тапшырыла.

14. Җирле үзидарә органнарының вәкаләтенә кермәгән мөрәҗәгать килгән очракта, ул аның вәкаләтенә туры китереп, дәүләт хакимияте органына җибәрелә.

## 4. Җаваплылык

15. Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре, коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре» аша алынган мәгълүмат белән эшләгәндә, конфиденциаль мәгълүмат белән эшләү өчен билгеләнгән таләпләрне үтәү өчен шәхси җаваплылык тоталар.

16. Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре, бу Нигезләмә таләпләрен бозганнары өчен, кануннарга туры китереп, җаваплылыкка тартылалар.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районында коррупция
юнәлешендәге мәсьәләләр буенча
«Язма корреспонденция өчен
хәбәрдарлык әрҗәләре» эшчәнлеге
турында нигезләмәгә
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»ннән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен алу акты

«__» ________ 20__ ел

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре» эшчәнлеге турында нигзләмәгә туры китереп, эш төркеме түбәндәге составта:

1.________________________________________________________________
______________________________________________________________
2.________________________________________________________________
______________________________________________________________
3.________________________________________________________________

20__ ел ның «__» _________ _____ сәгать _____ минутта түбәндәге адреста урнашкан коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»н ачуны башкарды: __________________________________
____________________________________________________________________

Билгеләнде
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
(әрҗәнең механик зарарланулары булуы яки булмавы, гражданнарның мөрәҗәгатьләре булуы)

Акт ______ биттән тора, _____ данәдә төзелде.

Эш төркеме әгъзаларының имзалары:
____________________/_________________________/
____________________/_________________________/
____________________/_________________________/

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр исемлеге

| № т/б | Мөрәҗәгать кемнән килде | Кире адресы | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| | | | |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының
2026 елның «16» июлендәге
11-77 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында коррупция юнәлешендәге мәсьәләләр буенча «Язма корреспонденция өчен хәбәрдарлык әрҗәләре»ннән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен алу буенча эш төркеме составы

| | |
|---|---|
| Лаврентьева<br>Ольга Александровна | Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы, эш төркеме җитәкчесе; |
| Лобачева<br>Ирина Игоревна | Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, эш төркеме секретаре; |
| Пузикова<br>Анна Николаевна | Яңа Чишмә муниципаль районы Советының кадрлар секторы мөдире, эш төркеме әгъзасы. |